| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.11.2019 № 1021

2020 елга Нурлат муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күпьюнәлешле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2009 ел, 31 декабрь, 939 нчы карары һәм Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга:

- Нурлат муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм Нурлат муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны;

- балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күпьюнәлешле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыруга 0,5 күләмендә норматив чыгымнар буенча төзәтү коэффициентын расларга.

2. “Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы индексы белән бер үк вакытта яңадан карауны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019 ел, 14ноябрь, 1021 номерлы

карары белән расланды

**Нурлат муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү буенча күпьюнәлешле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруның**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Урнашу урыны | Норматив чыгымнар, бер укучыга бер елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Эстетик-сәнгать | шәһәр җире | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җире | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җире | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җире | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җире | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җире | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |